| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЕЧЕ ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** *Кече Чынлы авылы* **КАРАР**

2019 елның 14 гыйнваре №42/2

Пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль хезмәт турында «2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә муниципаль вазыйфа билгән затларга хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 апрелендәге 30 номерлы карары белән расланган пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе һәм шартлары 1 пунктына кертергә "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында (редакциядә 23.05.2018 г.№31,11.09.2018 г. №35/3, түбәндәге үзгәрешләр:

икенче абзацны яңа киләсе редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турындф "2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә эштән азат ителгән затка әлеге карар нигезендә билгеләнгән ун тапкыр айлык акчалата бүләкләү түләнә.";

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Кече Чынлы авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - ФБП) түбәндәге документларны тәкъдим итә:

пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль вазыйфасын биләгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар;

муниципаль вазыйфа биләгән затның айлык акчалата бүләкләүләү турында белешмә;

җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган муниципаль вазыйфада һәм муниципаль хезмәттә эшләү стажы турында белешмә;

җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билетының күчермәләре;

муниципаль вазыйфа биләүче затның эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.

Әлеге Нигезләмәнең 1.4 пункты нигезендә документлар, пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, муниципаль вазыйфа биләгән затка яки муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында Карар кабул ителгәннән соң, 5 календарь көне эчендә тапшырыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы тарафыннан җирле бюджеттан акча бүлеп бирү турында Карар кабул ителгәннән соң 20 көн эчендә ФБП җирле үзидарә органнарына бюджет ассигнованиеләре һәм бер тапкыр акчалата түләү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәр итә.

Җирле үзидарә органы әлеге хәбәрнамәләр нигезендә муниципаль вазыйфа биләгән затка яки муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләмен башкара.

Акчалата бүләкләү бер тапкыр түләнә.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында интернет телекоммуникация челтәрендә авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Халитов Г.Ш.